**Р А С Л Ы Й М**
**Директор**
**_____________Җиһаншин И.И.**
**“___” ________________20__ел**
**МӨҺЕР**

# *Отчёт*

*Ислам динен кабул итүгә*
*1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсендә*
*2015-2016 нчы уку елында үткәрелгән чаралар*

## Корбан гаете

24 сентябрь көнне таң белән республикабыз мөселманнары мәчетләргә Корбан гаете намазын укырга ашыктылар. Төп бәйрәм чарасы Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, республикабыз мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм мөхтәрәм кунаклар, меңләгән дин кардәшләребез катнашында Кол Шәриф мәчетендә узды.

Ал мәчеткә җыелган халыкны Ильяс хәзрәт сәләмләде, аларга хаҗилар, башка төбәкләрдә имамчылык итүче мәдрәсә шәкертләре саләмнәрен җиткерде.

Иртәнге биштән мәчеттә Коръән аятьләре яңгырады. Алтынчы яртыда мәчет имамы Хәйдәр хәзрәт вәгазендә Корбан бәйрәменең мәгънәсен, Ислам кушканнарны аңлатып нәсихәтләрен җиткерде.

## Мәдрәсә мөгаллимнәре республика киңәшмәсендә катнашты

29-30 сентябрь көннәрендә Казанга республикабызда дини гыйлем бирүче мөгаллимнәр һәм мөгаллимәләр җыелды. Чара Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан, КФУ һәм РИУ белән берлектә оештырылган иде. Аның эшендә безнең мәдрәсә мөгаллимнәре дә катнашты.



Мөселман уку йортлары мөгаллимнәренең халыкара форумының беренче көне мәчетләр каршында эшләүче курсларда дини гыйлем бирүгә багышланган иде. Ягъни, форумга килгән 500ләп остаз дини башлангыч гыйлем хакында фикерләштеләр. Бүген исә сөйләшү мәдрәсәләр һәм дини югары уку йортлары хакында барды. Шуңа күрә дә чарада нигездә, мәдрәсәләр җитәкчеләре һәм мөгаллимнәре, Россия ислам университеты вәкилләре, галимнәре, шулай ук тәҗрибә уртаклашу ниятеннән килгән Марокко, Һиндстан дин белгечләре катнашты. Бүгенге көндә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте карамагында 9 мәдрәсә һәм югары дини белем бирүче Россия ислам университеты эшли. Нәзарәт тарафыннан уку-укыту стандартларын әзерләү максатыннан Уку-укыту - методик берләшмәсе оештырылды, аны мөфти урынбасары, профессор Рәфыйк Мөхәммәтшин җитәкли. Әлеге берләшмә тарафыннан әзерләнгән яңа программалар мәдрәсәләргә кертелә башлады.

**Агач утырту – изге гамәл!**

Әйләнә-тирәдә күпме генә агач булмасын, күңелне күтәрә торган яшеллек беркайчан да артык булмый. Бөтен тирә-якның көзен яшелләндерү эшендә икәнлеген күреп, мәдрәсә коллективы да үз өлешен кертергә булды. Бу эштә үзенең зур ярдәмен, күп еллар урман хуҗалыгы министрлыгында хезмәт иткән, Мансур хаҗи Әхмәтов күрсәтте.



«Агач утырту – изге гамәл», – дип Ильяс хәзрәт шәкертләрне бу эшкә димләде. Мәдрәсә Мәҗит Гафури урамына күчкәч тә, беренче эшне юкә агачлары утыртудан башлаганны да искә төшерде ул.

Мәдрәсә җитәкчесе шәкертләргә яшь куакларга күз-колак булуларын, ә яз-җәй айларында, кибеп китмәсеннәр өчен, су сибүләрен сорады.

Бергәләп тотынгач, эш тә тиз тәмамланды. Менә шулай итеп мәдрәсә ишек алдында кырык яшь чыршы барлыкка килде.

Үсентеләрне Саба (зәңгәр чыршы), Арча (чыршы), Кама (дүләнә), Биләр (гөлҗимеш) урман хуҗалыкларыннан кайтарган иделәр. Мәдрәсә җитәкчелеге бу оешма җитәкчеләренә зур рәхмәтен җиткерә, эшләрендә зур уңыш тели.

Шулай ук Фәннүр Шәүкәт улы Фәсхетдинов ярдәме белән өч дистә төрле-төрле сортлы алмагачлар үсентесе китерелде һәм мәчет әйләнәсенә утыртылды.

## Мәдрәсәдә хаҗиларны хөрмәтләү мәҗлесе узды



Мәдрәсәдә, җомга намазыннан соң, быел Хаҗ кылырга барган мөселманнар хөрмәтенә мәҗлес үткәрелде. Мәҗлескә шәкертләр, мөгаллимнәр, зыялы мөселманнар, мәчет картлары җыелган иде.

Быелгы хаҗ гамәле турында әнисе белән быел хаҗда булган Әнәс Әхтәм улы Локманов сөйләде. Ул халыкка тәфсилләп хаҗ кылу рәвеше турында сөйләде, үзләренең анда туган хисләре белән уртаклашты.

Әнәс хаҗи анда барулары белән чиксез бәхетле булулары турында белдерде, күңелем белән әле дә андамын диде.

Хаҗилар халыкны зәм-зәм суыннан авыз иттерделәр, күчтәнәчләрен өләштеләр һәм аш өстәленә чакырдылар. Ризык мулдан әзерләнгән, мәҗлескә килгән бар кешегә дә җитәрлек иде.

## «Ак барс» хоккей командасы капкачысы Эмиль Гарипов мәдрәсәдә корбан ашы уздырды



Танылган «Ак Барс» хоккей командасы капкачысы Эмиль Рамил улы Гарипов "Ислам динен кабул итүгә 1000 ел" исемендәге мәдрәсәдә Корбан ашы уздырды.

Чарада танылган спортчының әти-әниләре, туганнары, дуслары, имамнар, күренекле татар зыялылары, мәдрәсәсе шәкертләре һәм мөгаллимнәре катнашты.

Җыелган кунаклар башта ахшам намазы укыдылар. Мәҗлесне мәдрәсә ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин башлап җибәрде. Аннары кунаклар Әнәс хаҗи алып кайткан Зәмзәм суыннан авыз иттеләр. ТР МДНнең дәгъват бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров халыкка эчтәлекле вәгазь сөйләде. Ул барлык мөселманнарны яңа хиҗри 1437 ел белән котлады. Мөхәррәм аеның фазыйләтләрен шәрехләде. Корбан мәҗлесен оештыручыларга рәхмәт әйтте, чалган корбаннарның кабул булуын теләде.

Мәҗлес кунаклары Эмиль кардәшкә иң изге теләкләрен җиткерделәр. Тазалык-саулык, иманлы гамәлләр, яңа үрләр вә җиңүләр теләделәр. Җырчылар Илсаф һәм Ильяс Халиков мәҗлесне матур мөнәҗәтләр көйләп сәламләделәр.

## Мәдрәсәдә Иске Кулаткы мөслимәләре булып китте



Мәдрәсәдә шимбә көнне Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткы районы мөслимәләре кунак булды. Район өлкәнең көньягында, дала җирендә урнашкан. Административ үзәге — Иске Кулаткы бистәсе. Мәйданы 1180 км². Иске Кулаткы районына кергән 23 авылның барысы да диярлек татар авыллары. 96% – татарлар, 4% чуашлар яши. Казан белән арасы 450 километр чамасы.

Мәдрәсәне бу район белән күптәнге дуслык җепләре бәйли. Мәдрәсә мөгаллимнәре бик теләп Кулаткы укуларында катнаша, Районннан шәкертләр дә еш бирегә укырга килә. Әле бер ел элек кенә район имамнары да килеп мәдрәсәдә кунак булганнар, мөгаллимнәр белән очрашканнар иде.

Ерак юлны якын итеп килгән кардәшләрне Ильяс хәзрәт һәм мәдрәсә мөгаллимнәре каршы алды. Күрешеп хәл-әхвәлләрне сораганнан соң кунакларны аш өстәленә чакырдылар. Алар шәкертләр пешергән корбан ашыннан, гошер сәдакасына килгән яшелчәләрдән ясаган салатлардан авыз иттеләр, тәмле итеп чәй эчтеләр. Кулаткылар алып килгән күчтәнәчләрен, сәдакаларын бирделәр. Шәкертләр Коръән укып, Ильяс хәзрәт биргән күчтәнәчләргә, сәдакаларга дога кылды. Аштан соң кунаклар мәдрәсә белән танышты, намаз укыдылар. Мәдрәсә җитәкчесе Кулаткы мөслимәләренә Казанда чыккан китаплар өләште.

**Мәдрәсә шәкертләре көрәш буенча Татарстан чемпионатында катнашты**

12-14 ноябрь көннәрендә башкалабызда татарча көрәш буенча Татарстан Республикасының шәхси һәм команда исәпләренә узган чемпионатта Казанның Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә шәкертләре дә катнашты.

“Ак Барс” көрәш сараена дүрт йөзләп спортчы җыелган иде. Алар 10 авырлык категориясендә көч сынашты. Ярышлар тантаналы рәвештә 13 нче ноябрьдә башланды.

Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман



мәдрәсәсе шәкертләре дә ярышка килүчеләр белән бик теләп көч сынашты. Өченче курс шәкерте Гыйльманов Рамил 60 килограммга кадәрле авырлыкта чыгыш ясады. Беренче курс шәкерте Әхмәтшин Рушан 65 килограммга кадәрле категориядә көрәшсә, аның курсташы Садыйков Ирек 80 килограммга кадәр авырлыктагы батырлар белән бил алышты.

Ярышларга мөселман уку йорты шәкертләрен заманында атаклы бил алышучы булган Әнәс Әхтәм улы Локманов әзерләде һәм алып барды.

Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин сүзләренә караганда, уку-укыту барышында шәкертләргә спорт белән шөгыльләнү өчен зур мөмкинлекләр тудырыла.

**Татарстан мөфтие Казанның ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе шәкертләрен Мәүлид ән-нәби белән котлады**



21 декабрь көнне мәдрәсәдә Мәүлид ән-Нәбигә багышланган бәйрәм чарасы булды. Анда Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин һәм башка кунаклар катнашты.

Бәйрәм ачык дәрес формасында үтте. Мәдрәсә шәкертләре чакырылган кунаклар каршында татарча мөнәҗәтләр һәм салаватлар башкаруның төрле ысулларын күрсәтте.

Үзенең сәламләү сүзендә мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин шәкертләргә салават әйтүнең кайбер нечкәлекләрен ачты, әлеге гамәлнең Аллаһ каршында аерчу зур савапка ия булуы турында да әйтте.

“Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлләм кыямәт көнендә салават һәм сәламнар әйтүчеләр янәшәсендә булырмын дип әйтеп калдырган. Әлеге гамәлләребез белән без Аллаһ Тәгаләгә биргән нигъмәтләре, Пәйгамбәребез өчен рәхмәтебезне белдерәбез”, – дип әйтте мөфти хәзрәтләре.

Шуннан соң Дагстан кунакларының чыгышы булды. Мөхәммәд Шәфи һәм Яхъя Юсупов гарәп телендә нәшидләр башкарып мастер-класс күрсәтте.

Мәдрәсә җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин да шәкертләренә һәрдаим белемгә омтылырга, күркәм гамәлләр кылырга өндәде.

Раил Мөхетдинов татар стилендә башкарыла торган мөнәҗәтләрне шәкертләргә җиткерде.

**Мәдрәсәдә танылган хәйрияче рухына багышлап дога кылдылар**



4 гыйнварда Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсендә Мәүлид бәйрәмен уздырдылар. Пәйгамбәребезне (с.г.в.) олылауга һәм аның хакында гыйлемне арттыруга багышланган чарада нәзарәтнең дәгъват бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров, мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Бөтендөнья татар конгрессының Казан бүлеге җитәкчесе Фәрид Мифтахов, мәдрәсә мөгаллимнәре һәм шәкертләре катнашты.

Чарада Нияз хәзрәт Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) турында сөйләде, аның гамәлләре хакында бәян итте. Шулай ук чарада катнашкан мөнәҗәтләр башкаручы Ильяс Халиков касыйдә һәм салаватлар укыды.

Өйлә намазыннан соң чарага җыелганнар танылган хәйрияче 3 гыйнварда бакыйлыкка күчкән Әсгать Галимҗанов рухына багышлап дога кылдылар. Раббыбыз бик күп ятимнәргә, мохтаҗларга ярдәм кулы сузган Әсгать аганың урынын җәннәт түрләреннән итсә иде, дип сорадылар.

## Шәкертләр белән очрашу



14 гыйнварда Арчада Балтач мөхтәсибәтендә дини белем алучы студентлар белән очрашу булды. Чарада нәзарәтнең дәгъват бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров, Балтач мөхтәсибәтенең үзәк мәчете имам-хатыйбы, мәдрәсәнең Балтач филиалы җитәкчесе Рамил хәзрәт Бикбаев, мөгаллимнәр, “АРСКОЕ АТП” оешмасы җитәкчесе Рүзәл Баязитов, мөнәҗәтче Ильяс Халиков катнашты.

Нияз хәзрәт Сабиров үзенең чыгышында мөфти хәзрәтләренең сәламләүләрен һәм үгет-нәсыйхәтләрен җиткерде, белем алү әһәмияте турында вәгазь сөйләде.

“Шәригать турында белемнәребезне көндәлек тормышыбызда куллану кирәк. Пәйгамбәребез: “Адәм баласы вафат булганнан соң, бөтен эшләре туктый, бәлки бу эшләре генә артыннан барып, савап биреп торыр: халык өчен файда алырлык рәвештә калдырган гыйлеме, изге баласы, мирас итеп калдырган Коръән китабы, төзегән мәчете, юлчылар файдалансыннар өчен салдырган йорты, агызып калдырган елгасы, үзе сәламәт вакытында чыгарып калдырган садакасы. Шул нәрсәләрнең савабы үзе артыннан каберенә һаман барып торыр”, – дип сөйләде хәзрәт.

Ильяс Халиков төрле эчтәлектәге мөнәҗәтләр башкарды. Чара кысаларында Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләлаһү гәләйһи вә сәлләмнең тормыш юлына багышланган викторина оештырылды, җиңүчеләргә кыйммәтле бүләкләр тапшырылды.

**Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә шәкертләре галим Марсель Әхмәтҗанов белән очрашты**

19 февраль көнне Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан Югары мөселман мәдрәсәсе шәкертләре тарих дәресендә филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов белән очрашты. “Әйтер сүзләрем шушыдыр” дип исемләнгән дәрес-очрашуны тарих фәннәре докторы Наил Таиров алып барды.

Билгеле булганча, мәдрәсәдә дәрестән тыш чаралар, төрле бәйгеләр, спорт чаралары еш булып тора. Мондый очрашулар шәкертләрнең күңелендә якты хатирә булып саклана һәм ул зур тәрбияви әһәмияткә ия. Бер күрешү – бер гомер дигәндәй, бу юлы узган очрашу галимнәргә бирелгән сорауларга, фикер алышуларга бик бай булды.



Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, очрашуны башлап, уку йортының күренекле татар галимнәре белән һәрчак элемтәдә торуын ассызыклап узды. Атаклы галимебез Марсель аганың үз гомере дәвамында искиткеч зур хезмәт башкаруын – меңнән артык авыл зиратларындагы каберташ язуларын өйрәнеп чыгуын шәкертләргә җиткерде. Моннан тыш, Марсель Ибраһим улы – мәшһүр зыялыларыбыз Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэддин Фәхреддин традицияләрен дәвам итеп, татар шәҗәрәләрен өйрәнеп, уннан артык китап бастырган шәҗәрәче галим дә.

Халыкара Төрки академия академигы Марсель Әхмәтҗанов шәкертләрнең укуы белән кызыксынды, аларны библиография белән эшләргә өйрәтте. Һәр халыкның туган теле бөтен рухи байлыкның нигезе булуына басым ясап, үз ана телебезгә бик зур хөрмәт белән карарга кушты. “Мине әти-әнием 1946 нчы елда рус классына биргәннәр иде. Аллаһыдан тәкъдир шулай булган икән: укый алмадым мин анда. Аннары мин татар телендә укуга күчтем. Туган телемдә белем алу мине галим итте. – диде ул. – Сез татар милләтенә хезмәт итүчеләр булып җитлегергә тиешсез: татар телендә белем аласыз, китапханәгез бик бай, мөмкинлекләрегез бик зур”. Ул шулай ук татар халкының этник тарихы белән кызыксынырга, атамаларны өйнәнергә, татар халкының язма мирасы белән кызыксынырга чакырды. Шәҗәрәләрнең әүвәлге заманнарда ныклап җыелмавына борчылуын белдереп, күп тарихның югалуын, безнең көннәргә кадәр ирешмәвен әйтте. “Шәҗәрәләрне өйрәнү бөтен халыкта да киң таралмаган. Мин

аны алманнарда һәм рус дворяннары нәселендә очраттым. Татарларда исә ныклы нигезне Х.Әмирхан, Ш.Мәрҗани, Р.Фәхреддин салган. Аларның хезмәтләрендә шәҗәрәләр сакланып калган. Нәселегезне өйрәнегез. Моның өчен туганнарыңны барларга кирәк. Туган-тумачаларың белән элемтәне ялгау ул – динебездә бик тә хуплана торган гамәл. Нәсел агачыгызны шәҗәрә рәвешендә үк төзи алмасагыз да, бүгеннән сораша башлап өч-дүрт буынны язып куя аласыз – шуннан башлагыз”, – диде мөхтәрәм галимебез.



Марсель Әхмәтҗановтан шәкертләр татар тарихында якты эз калдырган биш шәхеснең исемен атауны сорадылар. “Кол Шәриф. Батырша. Гаяз Исхакый. Хәсән Туфан. Нәкый Исәнбәт. Болар – татар милләте өчен җанын бирергә әзер торган шәхесләр, халыкны саклап калу өчен ифрат зур тырышлык куйган кешеләр”, – дип җавап бирде ул. Галимнән шулай ук мәчетләр каршында эшләп килгән мәдрәсәләр турында да сорадылар. “Мәдрәсәләр тотып, белем эстәүдән өзелмәгәнбез. Нинди генә вакыт булса да. Мәдрәсәле халыклардан мин татарларны һәм үзбәкләрне генә атый алам. Алтын Урда чорында ук дөньядагы иң зур уку йорты – Ногмания мәдрәсәсе эшләгән. Казан ханлыгында иң зурысы – Кол Шәриф мәдрәсәсе. Уку-язуга, белемгә омтылыш шулкадәр көчле булган ки, татар дәүләтләре яулап алынганнан соң да мәгърифәткә, уку-язуга омтылыш сүнмәгән. Каганлык җитәкчеләренең каберендәге васыять язуы гына да ни тора: “Булган әйберне саклагыз!” Безнең көннәргә никадәр байлыгыбыз килеп иреште – менә шуны саклау безнең бурычыбыз. Беркайчан да төшенкелеккә бирелергә ярамый”, – дип тәгәлләде галим үз сүзен.

Мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Марсель Әхмәтҗановка очрашуга килгәне өчен рәхмәтен җиткерде һәм аңа “Рәхмәт хаты”н тапшырды, саулык-сәламәтлек теләде һәм безне яңадан-яңа фәнни ачышлары белән сөендереп торуын теләде. Галим исә үз чиратында үзенең яңа басылып чыккан китапларын мәдрәсә китапханәсенә бүләк итте һәм җомга намазында катнашты.

## Шакирды медресе пообщались с Тимуром хазратом Ибрагимовым

Казанском высшем мусульманском медресе имени 1000-летия принятия Ислама состоялся вечер, посвященный Дню защитника Отечества. На встречу с шакирдами пришёл подполковник Тимур хазрат Ибрагимов.




В 1995 году Тимур хазрат, будучи подполковником, поступил на дневное отделение данного медресе. Хазрат поделился с ребятами своими воспоминаниями о военной службе, о периоде обучения в религиозном учебном заведении и о недавних курсах повышения квалификации в г. Уфе по подготовке полковых имамов.

В свое время Тимур хазрат научился наматывать чалму у первого Главного казыя Татарстана Габделхака хазрата Саматова. Сейчас более двадцати пяти лет он учит этому шакирдов. Кроме того, Тимур хазрат талантливый пчеловод и обучает этому ремеслу и своих подопечных.

В конце встречи Тимур хазрату было задано много вопросов, на которые он дал исчерпывающие ответы. Тимур хазрат также напомнил хадис, в котором говорится: «Любовь к Родине – от имана».

## Мәдрәсә шәкертләре чалма бәйләргә өйрәнә

Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә шәкертләре чалма чалырга өйрәнә. Алар мәдрәсә үткәреләчәк чалма бәйләү бәйгесенә әзерләнәләр.



Остаз Тимур хәзрәт Ибраһимов чалма турында гомуми мәгълүмат бирде, аның әһәмияте, чалма киеп йөрүнең хасияте турында җиткерде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: "Чалма киеп укыган намаз, чалмасыз укыганына караганда, егерме биш тапкыр күркәмрәк, ә җомга намазы исә чалмасыз укыганына караганда җитмеш тапкыр кыйммәтрәк".

Ул шулай ук чалма киеп намаз укуның хасияте турында – 116 хәдис, ә сакал йөртүнең хасияте хакында 7 хәдис барлыгы турында әйтте.

Мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин шәкертләрне чалма бәйләү бәйгесенә яхшылап әзерләнергә һәм милли гореф-гадәтләребезне сакларга чакырды.

**Мәдрәсә шәкертләре танылган мөнәҗәтче белән аралашты**

26 февраль көнне Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсендә Татарстанның халык артисты, күренекле мөгаллим Миңгол Галиев белән очрашу узды.



Шәкертләргә ул үзенең тормыш юлы турында сөйләде, сәнгатьле сөйләм буенча мастер-класс үткәрде һәм һәр укучы белән индивидуаль дәрес алып барды.

Мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин Миңгол аганың танылган шәхес булуын шәрехләп, аның хәзерге дәрәҗәләргә тормышның бар ачысын-төчесен күреп ирешүе хакында җиткерде.

Хәзерге вакытта Миңгол Галиев Татар җыр мәктәбен булдырган һәм ул анда укучыларга татар моңы төшенчәсе, мөнәҗәтләр, милли кыйммәтләребез турында мәгълүмат биреп килә. “Аллаһы Тәгалә кешеләрнең авазын сихри иткән, – диде күренекле моң әһеле. – Без кешеләрнең хисенә үтә белерлек дәрәҗәдә сөйләшә-аралаша белергә тиешбез. Аудиторияне, халыкны әсир итү ике төрле була ала: кылыч белән һәм җан җылылыгы белән. Бүген, кызганыч ки, рухи тәрбия артка чигенеп бара. Кеше хәзер шайтан туе кебек музыканы тыңлап туйды инде, барыбыз да күңел моңына мохтаҗ”.

Кичә ахырында Миңгол Галиев шәкертләргә үзенең нәсыйхәтләрен җиткерде һәм киләчәктә дә мәдрәсә белән хезмәттәшлек итәргә вәгъдә итте.

## Шәкертләр танылган татар каллиграфы белән очрашты



4 март көнне Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе шәкертләре танылган татар хаттаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Нәҗип Нәкъкаш (Исмәгыйлев) белән очрашты.

Нәҗип Нәкъкаш — татар мәдәниятендә каллиграфия сәнгатен яңадан торгызу, саклау һәм үстерүдә биниһая эшләр башкарган шәхес. Ул мәдрәсә шәкертләренә үзенең тормыш юлы турында сөйләде, эшләгән хезмәтләре белән таныштырды һәм шәкертләргә мастер-класс үткәрде. Иң истә калганы – һәр шәкертнең тограсын ясау булды.

Нәҗип Нәкъкаш быел Татарстанның рәссамнар берлеге тарафыннан Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә кандидат буларак тәкъдим ителде. Нәҗип абый үз хезмәтләрендә Г.Тукайның иҗади мирасы белән таныштырып, шагыйрьнең егерме биштән артык хезмәтеннән өзекләрне татар каллиграфиясе ысулы белән язганлыгын әйтте.

Бүгенге көндә гарәп каллиграфиясе искиткеч зур тизлек белән планетабызда зур үсешкә ирешә. Нәҗип абый, шулай ук, халыкара күргәзмәдә катнашкан хезмәтләре белән таныштырып, үзенең хезмәтләре кайларда саклану турында да мәгълүмат җиткерде.

Мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Нәҗип Фәйзрахман улының милләтебездә уникаль шәхес булуын ассызыклап, шәкертләргә аннан мөмкин кадәр күбрәк дәресләр алып калырга, татар шәмаилләренең эшләнеше белән кызыксынырга, тогралар ясарга өйрәнергә өндәде.

Нәҗип Нәкъкаш – меңнән артык тогра авторы, шуларның дүрт йөздән күбрәге пыялада эшләнгән. Мондый күләмле иҗатны бары тик төрле яктан әзерлеге булган галим кеше генә башкара ала. Ул үзе дә: «Монда гарәп язуын да су эчкән урынына күрергә кирәк, монда Коръәнне дә, хәдисләрне дә, гомумән, тарихны да яхшы белү сорала. Фарсы телен белү дә зарур. Сәнгатьнең бу төре әдәбият һәм дин белән катнашкан. Йолалардан, традицияләрдән дә хәбәрдар булуың мәслихәт. Әлбәттә, һәрбер рәссам боларның барысын да булдыра алмый. Шунлыктан әлеге сәнгать – хаттатлык иҗаты серләре сирәк каләм ияләренә генә ачылучан», – дип белдерде.



Нәҗип абый – катлаулы һәм мактаулы иҗат юлын сайлаган галим. Архивларда үз тикшерүчесен көтеп яткан күп кенә рухи мирас әсәрләрен халыкка кайтарды. Каллиграфия сәнгатен ялыкмыйча пропагандалап, үзе артыннан күпләгән яшьләрне ияртүгә иреште.

# Мәдрәсә шәкертләре чалма чолгау бәйгесендә көч сынашты

16 март көнне Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе шәкертләре арасында чалма чолгау бәйгесенең финал өлеше узды.



Бәйге мәдрәсәбезнең III курс шәкерте Гыйльманов Рамилнең Коръән укуы һәм Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыевның дога кылуы белән башланып китте.

Шунысын да искәртеп узарга кирәк, чалма чолгау бәйгесе мәдрәсәбездә беренче тапкыр үткәрелде. Бәйгенең баш жюрие һәм җиңүчеләргә приз тәкъдим иткән Җәлил хәзрәт Фазлыев ассызыклап узганча, мондый төр бәйгеләр борынгыдан килгән традицияләребезне саклап калырга һәм торгызырга ярдәм итәләр. Баш казый тарафыннан, мәдрәсәдә әлеге чалма чолгау бәйгесе зур хуплау табып, аны киләсе уку елында барлык мәдрәсәләр катнашында уздырып, бер мәйданда көч сынаштыру тәкъдиме яңгырады.

Әлбәттә, узган гасыр ахырында чалма чалу тәртипләре халкыбызның күренекле дин әһеле, Татарстанның беренче баш казые Габделхак хәзрәт Саматов (1930-2009) тарафыннан торгызыла. Шунысы игътибарга лаек, Габделхак хәзрәтнең үз кулы белән 2001 нче елда эшләнгән чалмасы мәдрәсәбезнең музеенда саклана. Бүген аны бәйгегә килүче һәркем күрә алды. Катнашучылар игътибарына шулай ук Урта Азиядә һәм Төркиядә ясалган чалмалар да күрсәтелде.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: “Чалма киеп укыган намаз, чалмасыз укыганына караганда, егерме биш тапкыр күркәмрәк, ә җомга намазы исә чалмасыз укыганына караганда җитмеш тапкыр кыйммәтрәк”, – дигән. Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин шәкертләрне мөмкин кадәр күбрәк тәҗрибә туплап калырга чакырды. “Мәдрәсәбез остазы Тимур хәзрәт Ибраһимов дәресләрдән буш вакытта се-



зне чалма чолгау серләренә төшендерде. Аңа Аллаһының рәхмәте булсын. Остазларыбыздан өйрәнеп, аны башкаларга да җиткерик”, – диде ул. Ильяс хәзрәтнең сүзләрен куәтләп, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт: “Ислам динендә баш киеме зур әһәмияткә ия. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм беркайчан да баш киемсез йөрмәгән. Чалма киеп намаз укуның хасияте һәм биреләчәк саваплары хакында йөздән артык хәдис билгеле”, – дип өстәде.

Жюри сыйфатында әгъза булып катнашкан милләтпәрвар шәхесебез, Бөтендөнья татар конгрессының Казан бүлеге җитәкчесе Фәрид Мифтахов шәкертләрнең эшенә зур бәя бирде һәм конгресс рәисе Ринат Закиров исеменнән татар әдипләренең басылып чыккан китапларын бүләк сыйфатында таратты.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең мәгариф һәм фән бүлеге мөдире Айдар хәзрәт Карибуллин шәкертләрнең әлеге һөнәр башлангычларында уңышлыклар теләде һәм киләчәктә дә милли гореф-гадәтләребезне саклауда әйдәп баручылардан булырга чакырды.

Конкурста җиңүче булып икенче курс шәкерте Закиров Илназ танылды. Икенче урында – Рамил Гыйльманов (III курс), өченчедә – Ильяс Рәхмәтуллин (II курс). Аларга Җәлил хәзрәт Фазлыевның махсус бүләге һәм дипломнар тапшырылды.

**Мәдрәсәдә Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулу уңаеннан “Мин кулыма Китап алам...” дип исемләнгән бәйге узды**



25 мартта Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсендә беренчеләрдән булып Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулу уңаеннан “Мин кулыма Китап алам...” дип исемләнгән бәйге узды.

Бәйге барышында шәкертләр халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның (1886-1913) дини тематикага кагылышлы шигырьләрен яттан сәнгатьле итеп сөйләде. Әлеге чара өч номинациядә узды һәм шәкертләрнең чыгышы мәртәбәле жюри тарафыннан бәяләнде.

Чара җомга намазыннан соң Коръән укып һәм дога кылып башланып китте. Килгән кунакларны сәламләп, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе мөдире Ильяс хәзрәт Җиһаншин: “Габдулла Тукай – халкыбызның иҗат даһилыгын мәңгеләштереп калдырды, үз заманының иң зур һәм иң җитди мәсьәләләренә җавап бирде”, – дип белдерде.

Катнашучылар Габдулла Тукайның “Туган тел”, “Китап”, “Васыятем”, “Таян Аллага”, “Алла гыйшкы хакына”, “Тәэссер”, “Мигъраҗ”, “Ана догасы”, “Тәүбә вә истигъфар”, “Туган авыл”, “Йокы алдыннан”, “Эш”, “Бәйрәм бүген”, “Васыятем” һ. б. шуның кебек күп еллар шәкертләр тарафыннан яратып сөйләнеп килгән шырьләрне башкарды.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәгариф мәсьәләләр комитеты рәисе һәм бәйгенең жюри рәисе Разил Вәлиев шәкертләрнең чыгышына югары бәя бирде, бүләкләрен тапшырды һәм үзенең Габдулла Тукайга атап язган шигырен укыды.

“Мин кулыма Китап алам...” беренче шигырь укучылар конкурсының жюри әгъзалары – Татарстан мөфтие урынбасары, Россия ислам институты ректоры Рәфикъ Мөхәммәтшин, “Җыен” фонды директоры Фуат Рәфыйков, Бөтендөнья татар конгрессының Казан бүлеге җитәкчесе Фәрид Мифтахов, Габдулла Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры директоры Мансур Ярмиев өч номинациядә җиңүчеләрне ачыклады.

“Габдулла Тукай шигырен аһәңле башкаручы” номинациясендә җиңүче булып “Тәүбә вә истигъфар” шигыре белән III курс шәкерте Хәйруллин Айнур танылды. “Габдулла Тукай шигырен иң оста башкаручы” номинациясендә беренче урын “Китап” шигырен сөйләгән Әхмәтҗанов Рушанга (I курс) бирелде. “Габдулла Тукай шигырен иң үтемле башкаручы” номинациясендә Садыйков

Иреккә тиңнәр табылмады – ул Габдулла Тукайның “Эш” шигырен сәнгатьле сөйләп беренче урынга лаек булды.

Җиңүчеләргә һәм барлык катнашучыларга Бөтендөнья татар конгрессыннан Азат Садриев әзерләп килгән истәлек бүләкләре – Габдулла Тукайның шигырь китаплары һәм “Габдулла Тукай иҗатында Коръән мотивлары” дип исемләнгән хезмәт тапшырылды.

Татарстан Республикасы мөфтие урынбасары, сәясәт фәннәре докторы Рәфикъ Мөхәммәтшин шундый күркәм чара оештыручыларга рәхмәтен җиткерде һәм Габдулла Тукай иҗатына кагылышлы бәйгеләрне башка дини уку йортларында да уздырырга кирәклекне әйтте. Ул шулай ук Г.Тукай иҗатының дөнья әдәбияты тарихында тоткан урынына басым ясады һәм татар әдәбияты тарихында исемнәре билгеле булган башка әдипләрнең дә иҗатын өйрәнергә чакырды.



Мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин жюри әгъзаларына, аерым алганда Разил Исмәгыйль улына фидакарьлеге өчен рәхмәтен белдерде һәм яңадан-яңа иҗади уңышлар теләде.

**Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәдә очрашу узды**



8 апрель көнне Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсенә очрашуга Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батыр килде.

Мәдрәсә мөдире Ильяс хәзрәт Җиһаншин, кунак белән таныштырып, Рөстәм хәзрәтнең хәнәфи мәзһәбен һәм Әбу Хәнифәнең тормыш юлын һәм мирасын өйрәнү юнәлешендә эзлекле эшләвенә басым ясап, соңгы елларда милли хәзинәбезне саклау өлкәсендә дә җиң сызганып татар шәмаилләрен барлауда хезмәт куюын билгеләп узды.

Рөстәм хәзрәт Батыр һәртөрле галимнәр, зыялылар белән очрашуларның дәвамлы булуын теләде һәм мөселман халыкларының һәркайсында ислам каллиграфиясенең үзенә генә хас традицияләре, үсеш үзенчәлекләре булуын җиткерде. “Татарлар да гомуммөселман каллиграфиясе үсешенә үзеннән лаеклы өлеш керткән. Халкыбыз шамаил ясауның уникаль тәртибен булдырган: татар шамаилләре элек-электән пыялага язылып, ялтыравык фольга файдаланып һәм милли бизәкләр төшереп эшләнгән”, – диде ул.

Очрашу дәвамында Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары мөселман архитектурасы һәм бизәлеш сәнгатенә хас орнаментлар турында да кызыклы мәгълүматлар бирде.

Ахырдан Рөстәм хәзрәт Батырга мәдрәсәнең хәзинәсе булган, кулдан-кулга йөреп гасырлар дәвамында укылган борынгы басма Коръән нөсхәсе тапшырылды һәм җомга намазы укылды.

**Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә шәкертләре Габдулла Тукай турында истәлекләр китабын тәкъдир итү кичәсендә катнашты**

19 апрельдә Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә (Казан, Кремль ур., 33) татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайга багышланган «Тукай – ядкярләрдә» исемле ике томлы җыентыкны тәкъдир итү кичәсе узды. Әлеге китапны “Җыен” фонды башкарма директоры Фоат Рәфыйков тәкъдиме вә ярдәме белән филология фәннәре докторы Рәмил Фәнәви улы Исламов, КФУның татарны өйрәнү һәм тюркология кафедрасы доценты Җәүдәт Сәлим улы Миңнуллин төзегән. Әлеге җыентыкта барлыгы 670 берәмлек материал тупланган. Шуларның 599 берәмлеге гарәп хәрефендәге чыганаклардан гамәлдәге татар алфавитына беренче мәртәбә күчерелеп, җыентыкка кертелгән.



Габдулла Тукайның туына 130 ел тулуга багышланган әлеге кичәне Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәнең I курс шәкерте Рушан Әхмәтҗанов шагыйрьнең “Китап” шигыре белән ачып җибәрде.

Татарстан Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәгариф мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, мәдрәсә шәкертләренең әзерлегэн югары бәяләп, мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншинга зур рәхмәтләрен ирештерде. Үсеп килүче буынны милли вә дини рухта тәрбияләүдә киләчәктә дә уңышлар теләде һәм шушы изге эшләрнең дәвамлы булуын теләп, татар халкы яшәгән һәр төбәктә Габдулла Тукайның иҗаты өйрәнелүен, аның шигырьләре ятланып сөйләнүе турында җиткерде. Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсендә быел, беренчеләрдән булып, Габдулла Тукайның шигырьләрен сәнгатьле уку буенча “Мин кулыма Китап алам...” конкурсы узган иде. Разил Вәлиев шәкертләрнең Г.Тукайның шигъри мирасын өйрәнүдә зур тырышлык күрсәтүләренә басым ясап узды һәм гарәп-фарсы сүзләре күп булган шигъри юлларны да җиңел, аңлаешлы, матур итеп җиткерә алулары хакында әйтте. Мәдрәсәбезнең III курс шәкерте Айнур Хәйруллин Г.Тукайның “Тәүбә вә истигъфар” шигырен сөйләде.

“Тукай – ядкярләрдә” китабын тәкъдим итеп, филология фәннәре докторы Рәмил Исламов Г.Тукайның дингә карашы турында шагыйрьнең замандашы Шәһеретдин Шәрәфнең (1877-1938) истәлегенә игътибар юнәлтергә өндәде: “Син милли шагыйрь бит, дини хисләргә дә шул дәрәҗәдә әһәмият бирәсеңме?” – дип сорагач, Тукай: “Дөньяда динсез бер милләт тә юк, бөтен милләтләр дин-

ле булганда, без генә динсез булып кала алмамыз. Халкымызда миллиятьләре сакланган мөддәттә, диннәре дә сакланачагына ышанам. Миллиятьләрен яхшы саклый алуларында гына азрак шөбһәм бар. Мин һәрвакыт дин берлә миллиятьнең һәр икәвесенә тигез әһәмият бирү тарафындамын", – диде".

Кичә дәвамында шәкертләр Габдулла Тукай премиясе лауреатлары Разил Вәлиев, Зиннур Мансуров, Рәдиф Гаташ, Әзһәр Шакиров, Гәрәй Рәхим, Вахит Имамов белән таныша-аралаша алды. "Мәдәни җомга" газетының баш мөхәррире, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Тукай премиясе иясе Вахит Имамов Габдулла Тукайның Мотыйгулла хәзрәт Төхвәтуллин тәрбиясендә җитлегүен әйтеп узды. Мисал өчен, Габдулла Кариев үзенең истәлегендә: «Габдулла әфәнде гомуми дәрескә дамелла Мотыйгулла хәзрәткә утырадыр иде. Габдулла әфәнде мәдрәсәдә иң галим, иң үткен, зирәк шәкертләрдән хисаплана иде. Дамелла Мотыйгулла хәзрәт Мисырда укыган бер галим фазыйль (башкалардан аерылып торучы) кеше... иде», — дип яза.

Әлеге кичәне Разил Исмәгыйль улы Вәлиевның алып баруы юкка түгел, чөнки ул "Җыен" фондының рәисе вазыйфасын башкара. Кичәдә катнашучылар әлеге «Тукай – ядкярләрдә» исемле ике томлы китапны, Тукайның алты томлыгыннан кала, гасыр казанышы дип бәяләргә өлгерделәр дә инде. Р.Вәлиев шулай ук Президентыбыз фәрманы белән Казандагы Тукай музее төзекләндереләчәге, Тукай энциклопедиясе әзер булачагы хакында да җиткерде. Шулай ук Кырлардагы музей да ремонтланачак.

Җыентыкта урын алган күп кенә истәлекләр, мәкаләләр халкыбыз тарафыннан үтәлеп килгән гореф-гадәтләрне һәм дини традицияләрне өйрәнү, аерым алганда безнең җирлектә таралыш алган хәнәфи мәзһәбен саклау юнәлешендә дә зур чыганак булып хезмәт итә ала. Мисал өчен, "Тукаевны дәфен" дигән мәкаләдә болай дип искә алына: "Сәгать бер туларга чирек калганда Зариф, Кәшшаф, Касыйм вә Борһан хәзрәтләр илә бергә җыелган халыкның бәгъзеләре тәһлил укыдылар...".

## Татарстан мөфтие – Балтачта




21 апрель көнне Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Балтач мөхтәсибәтенә эшлекле сәфәр кылды. Сәфәрен мөфти район башлыгы Рамил Нотфуллин белән очрашудан башлады. Әлеге очрашуда, шулай ук Балтач районы имам-хатыйбы, баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев катнашты.

Камил хәзрәт җирлек җитәкчесенә дини эшләрне алып баруда теләктәшлек белдергәне өчен рәхмәтен белдерде. Балтачта яңа төзелгән “Ислам нуры” мәчетен ачу зур эш булуын билгеләп узды. Әлеге мәчет 8 нче апрельдә район үзәгендә өченче иман йорты булып ачылды.

Район башлыгы белән очрашудан соң мөфти хәзрәтләре Балтач мәдрәсәсендә гыйлем алучыларның чыгарылыш кичәсендә катнашты. Биредә ул дини гыйлем алуның зур мәртәбә булуын билгеләп узды һәм барлыгы 43 шәкерткә дини гыйлем үзләштерүләре хакында дипломнар тапшырды.

Әлеге тантанада шулай ук Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Бөтендөнья татар конгрессының Казан бүлеге җитәкчесе Фәрид Мифтахов, Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе районнары имам-мөхтәсибе Мансур хәзрәт Җәләлетдин, Балтачның Җамигъ мәчете имам-хатыйбы, мәдрәсәбез мөгаллиме Рамил хәзрәт Бикбаев, күрше-тирә районнарның имам-мөхтәсибләре, чакырылган кунаклар катнашты.





Чара Коръән уку белән башланды. Чыгарылыш шәкертләре алдында чыгыш ясап, Татарстан мөфтие беркайчан да алган белемнәр белән генә туктап калмаска өндәде һәм нәсыйхәт рәвешендә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисен китерде: “Бишектән ләхеткәчә белем алыгыз”. Аннары мөфти хәзрәтләре һәрбер чыгарылыш укучысын тәбрикләде һәм аларга дипломнар тапшырды.

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин район башлыгы Рамил Нотфуллин белән әңгәмә корганнан соң Алан мәктәбендә районда бара торган әхлак дәресләренең йомгаклау өлешендә катнашты. Үзәк мәчеттә 7 чыгарылыш мәдрәсәне тәмамлаучылар белән очрашты, аларга дипломнар тапшырды. Шулай ук Балтачта яңа ачылган «Ислам нуры» мәчетендә булды, үзенең соклануын һәм рәхмәтен җиткерде.

Чыганак: *http://www.baltaci.ru/*

**Мәдрәсә шәкертләре Җәгъфәр хәзрәт Мөбарәк белән очрашты**

22 апрель көнне, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсендә танылган дин әһеле Җәгъфәр хәзрәт Мөбарәк белән очрашу узды.

Җәгъфәр абый – безнең мәдрәсәбез мөгаллимнәренең дә олуг остазы. Дин ирεге бирелгәч, анда күп кенә булачак мөфтиләр, дин әһелләре белем эстәгән. Җәгъфәр хәзрәтнең шундый шәкертләренең берсе – мәдрәсәбез мөдире Ильяс



хәзрәт Җиһаншин дини күтәрелеш елларында Җәгъфәр Мөбарәкнең фидакяр хезмәте хакында шәкертләрне таныштырды. Татар рухани мирасын кайтару юлында аның бүген дә армый-талмый хезмәт куюын ассызыклады һәм революциягә кадәр татар галимнәре тарафыннан язылган дини-фәнни хезмәтләрне өйрәнергә, библиография белән эшләргә кушты. Билгеле булганча, Җәгъфәр абый, 1991 нче елдан башлап, СССР таркалганнан соң Казанда ачылган беренче мәдрәсәдә, ун ел дәвамында татар дин галимнәренең хезмәтләре белән остазлык кыла.

Җәгъфәр Муллахмәт улы 1940 нчы елның 15 нче июнендә Луган өлкәсе Сергов районы Брянский авыл җирендә, ягъни Донбасста, шахтёр гаиләсендә дөньясында килә.

Очрашу барышында ул шәкертләрнең сорауларына җаваплар бирде, басылган китаплары белән таныштырып узды.

Җәгъфәр хәзрәт, тәҗвид фәненә кагылышлы ошбу авторларның китапларын хәзерге татар әдәби теленә тәрҗемә итеп, үзе шул китаплар белән 2000 нче елга кадәр мәдрәсәбездә дәрес бирә: Габдрахман Карабаши, имам Сәүбән, имам Гомәри, Шәһит Гауни, Сөнгатулла Бикбулат, Салихҗан Баруди, Галимҗан Баруди; Кыйраәти Куръән фәне буенча – Әхмәтһади Максуди, Нәҗип Думави хезмәтләреннән укыта.

2000 нче елдан алып 2003 нче елга кадәр дини әдәбиятны тикшерүче булып Татарстан Диния нәзарәтендә эшли.

Бүгенге көнгә илледән артык исемдәге китаплары дөнья күрә, күбесенең тиражлары 50 мең данәдән дә артып китә.

Диния нәзарәтендә эшләгәндә беренче басылган китабы – “Хәтер дәфтәре” (2002). Анда танылган дин галиме һәм мөгаллимнең Исламиятнең асылында яткан рухани-әхлакый кыйммәтләр, республикабыздагы дин вә мәгыйшәт торышы, Татарстан Диния нәзарәте һәм мөфтиләр тарихыннан күренекле вакыйгалар бәян ителә.

2002 нче елда Җәгъфәр абый Мөбарәк тарафыннан эшләнеп редакцияләнгән “Кыйссасел-әнбия” китабы узган елны “Хозур” нәшрият йорты тара-

фыннан кабаттан дәреслек сыйфатында нәшер ителде. Ул “Мирас” журналында да 2002-2003 нче елларда ай саен басылып килә. Хәзер әлеге уку-укыту әсбабы Россиянең барлык төбәк мөфтиләренә җибәрелде.

Соңгы басылып чыккан китабы – “Иблис, җен, шайтан, гыйфрит...” (2 кисәктән тора). Ул “Хозур” нәшриятында басылып, бүгенге көндә укучыларга таралып бетте. Әлеге китап “Шура” (Ризаэддин Фәхреддин чыгарган, 1908-1918 нче еллар), “Әд-дин вәл әдәп” (Галимҗан Баруди чыгарган), “Мәгълүмат” журналларында басылган мәгълүматларны файдаланып төзелгән.

Җәгъфәр абый белән очрашу бик күңелле узды, шәкертләр аның киләчәктә дә очрашуга килүен сорадылар.

**Нияз Сабирҗанов**
Чыганак: *http://dumrt.ru/*

**Буа шәкертләре Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә белән танышты**

22 апрель көнне Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе эшчәнлеге белән Буа мәдрәсәсенең кичке бүлегендә укучы иллегә якын шәкерт танышып китте.

Килгән кунаклар, аерым алганда, Яңа бистәнең күрке – Ал мәчет бинасында урнашкан мәдрәсә буенча экскурсия ясады, уку классларын, китапханәне, аш



бүлмәсен, музейны карады, мәдрәсәнең көндезге бүлегендә укучы шәкертләр белән аралашты. Килгән кунакларның сораударына Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин җавап бирде. Буа мәдрәсәсе шәкертләре мәдрәсәнең ике йөз елдан артык чал тарихы булган бинада урнашуына, шәкертләрнең умартачылык һөнәре асылына төшенүләренә сокулануларын җиткерде. Алар шулай ук мәдрәсә тарихы сәхифәләре бик ачык бирелгән музейда да булды. Биредәге иң күркәм экспонатларның берсе – Габделхак хәзрәт Саматовның чапаны һәм чалмасы белән таныштырып, мәдрәсәбез җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин бүген дә уку йортының Саматов рухын сакларга тырышуы хакында әйтте.

Буа мәдрәсәсенең директоры, тарих фәннәре кандидаты Рәшид хәзрәт Маликов, бик җылы һәм матур каршы алып, ике як өчен дә бик файдалы очрашу үткәргәннәре өчен, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе җитәкчелегенә зур рәхмәтләрен ирештерде. Мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин исә, намаздан соң, очрашу ахырында һәрбер кунакка календарь бүләк итте һәм, изге теләкләрен җиткереп, алга таба да очрашуларның дәвамлы булуын теләде. Мондый күрешү-фикер алышулар алга таба мәдрәсәләр арасындагы дуслыкның тагын да ныгуына, үзара хезмәттәшлек итүнең, тәҗрибә алышуның көчәюенә сәбәпче булса иде.

**Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсендә диплом тапшыру тантанасы узды**

27 апрель көнне, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсендә кичке бүлекне тәмамлаган 12 шәкерткә дипломнар тапшыру тантанасы узды.



Чыгарылыш шәкертләрен, өч ел дәвамында укып, имтиханнарны яхшы тапшырып һәм диплом эшләрен уңышлы яклаулары белән мәдрәсәбез ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин тәбрикләде. Ул килгән кунакларны мәдрәсәбез тарихы белән таныштырып, гыйлем алуның әһәмияте турында сөйләде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисен җиткерде: "Гыйлем иясе (галим), яки гыйлем алучы (шәкерт), яки гыйлемне тыңлаучы, яки гыйлемне сөюче бул. Ләкин бишенчесе (гыйлемне дошман күрүче) булма, һәлак булырсың". Моннан аңлашылганча, һәркайсыбызга гыйлемле, белемле булып, шул гыйлемне башкаларга да өйрәтү тиеш булу хакында әйтте. Ильяс хәзрәт, сүзен йомгаклап, мәдрәсәне тәмамлаучыларны гыйлем үзләштерү һәм аны тарату юлында тукталмаска чакырды.

Аннары мәдрәсәбезнең уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары Аяз хәзрәт Мингалиев сүз алды. Ул шәкертләргә гыйлем алу өстендә һәрдаим эшләргә һәм белгәннәреңне башкаларга да өйрәтергә кушты. "Белгәнеңне башкаларга өйрәтмичә утыру тыйнаклык була алмый. Шулай ук мәҗлесләрдә: "Мин барысын да беләм", – дип, гыйлемле кешеләрне дә уздырып сөйләү килешә торган гамәл түгел", – дип искәртте һәм бер чиктән икенче чиккә ташланмыйча, һәрвакыт үз өстеңдә эшләргә, камилләшергә чакырды.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның сәламен һәм тәбрикләү сүзләрен җиткерде, гыйлем ияләре турында Коръән аятьләрен искә төшереп узды: "Галим кеше Аллаһының җәзасыннан курка (хәрәмнәрдән тыела, Аллаһы риза булган гамәлләр кыла)" ("Фатыр" сүрәсе, 28 нче аять). "Белемле кеше булып саналыр өчен биш шартны үтәргә кирәк: 1) Остазыңны игътибар белән тыңларга; 2) дәрес вакытында сөйләшмәскә; 3) остазның сүзләрен истә калдырырга тырышырга; 4) алган белемнәреңне тормышта кулланырга; 5) белемнәрне башкаларга да ирештерергә. Сезнең һәрбарчаларыгызга да зур уңышлар телим, барыгызга да гыйлем алуны дәвам итәргә, Аллаһы ризалыгы өчен изге гамәл-гыйбадәтләр кылып яшәргә насыйп булсын", – дип, ихлас теләкләрен җиткерде.

Бөтендөнья татар конгрессының Казан шәһәре бүлеге җитәкчесе Фәрид Мифтахов милли гореф-гадәтләребезне онытмаска, динне һәм милләтне һәрвакыт бергә, бер-берсеннән аермыйча алып барырга кушты.

Мәдрәсәбезнең фикъһ мөгаллиме Рөстәм хәзрәт Ясәвиев халкыбызның һәрвакыт белемгә, мәгърифәткә омтылганлыгы хакында җиткерде һәм татар халык мәкале белән: “Теләп алган картам (карта – хайван эчәгесе күздә тотыла), тешли-тешли тартам”, – дип әйтте, – ягъни, гыйлемне дәвам итәргә һәм үзең белгәнне авырлык-сынауларга да карамыйча, аны башкаларга тапшыру лазем булуы хакында әйтте. Йөзгә кызыллык китермичә, йөкне уртак рәвештә бар тешебез белән тырышып-тырмашып тартып барырга кушты.

Мәдрәсәбезнең әдәп мөгаллимәсе Фәния абыстай Җәләлиева дин әһелләренең, абыстайларның халыкка якын булуларын теләде һәм шәригать хөкемнәрен халыкка җиткергәндә нык торырга кушты. Ул шулай ук дини һәм әдәби мирасыбызны яхшылап өйрәнүебезне теләде.

Мәдрәсәбезнең Коръән тәфсире мөгаллиме Равил хәзрәт Бикбаев: “Гыйлем алу юлына баскан кеше җәннәткә якынаючылардан булыр. Бу хакта хәдисләрдә әйтелә”, – диде һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлламнең шундый сүзләрен китерде: “Гыйлем алу юлына чыккан кеше хаҗ кылу (кайбер риваятьләрдә гомрә кылу дип килә) савабын алыр”.

Мәдрәсәбезнең кичке бүлек җитәкчесе Ибраһим хәзрәт Шамилов чын күңелдән гыйлем үзләштергән барлык шәкертләргә дә рәхмәт сүзләрен җиткерде һәм динебез юлында армый-талмый озак еллар бергә хезмәт итүебезне теләде.

Шуннары унике шәкерткә урта дини белем алу хакында дипломнар тапшырылды, өйлә намазы укылды һәм гакыйка корбаныннан мәҗлес уздырылды.

## Остазларның каберләрен зиярәт иттек

Ислам динен кабул итүнең мең еллыгы исемендәге мәдрәсә әһелләренең (аның мөгаллимнәренең, шәкертләренең, бу уку йортын бетереп имамчылык



итүчеләрнең) күркәм гадәте бар: ел саен 2 май көнне Яңа бистәдәге татар зиратында, кунаклар чакырып, остазларны искә алалар. 2005 елдан бирле ел саен үткәрелә торган чара инде Казан, Татарстан буенча гына түгел, инде бөтен татарлар яшәгән төбәкләрдә танылды. Шуның өчен быел да Татарстанның, РФнең төрле төбәкләреннән дин әһелләре, милләт зыялылары килде. Быелгы чарада Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, Ханты-Манси автоном округының мөфтие, төбәкнең татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Таһир хәзрәт Саматов, Самара өлкәсе мөфтие Талип хәзрәт Яруллин, Чуваш Республикасы Диния нәзарәте рәисе Мәнсур Хайбуллов, Татарстанннның Баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Бөтендөнья Татар конгрессының Казан оешмасы рәисе Фәрит Мифтахов, күренекле имамнар, татар зыялылары, журналистлар, мөгаллимнәр, шәкертләр катнашты.

Габделхак хәзрәт Саматов, Габделхак хәзрәт Каюмов, Гарифулла хәзрәт Гайнуллин, Зәкәрия хәзрәт Минвәлиев, Әхмәтһади Максуди, Галимҗан һәм Салихҗан Барудилар, Габделхәбир хәзрәт Яруллин һәм башка күркәм затлар баш очларында Коръән аятьләре укып, дога кылып мәшһүр бабаларыбызның рухлары алдында баш идек бүген.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләрнең кабере янында тукталып, аның рухына дога кылды. Киләчәктә Мәрҗани мирасын тагын да киңрәк колач белән өйрәнергә кирәклегенә басым ясады. Казан (Идел буе) федераль университетында саклана торган библиографик характердагы хезмәт – «Вафийәт әл-әслаф...» кульязмасын телгә алды. Әл-Әзһар университетында Мәрҗани әзерләгән китаплар буенча дәрес бирелүен әйтеп узды.

Татарстан мөфтиятендә дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллин каберенә җиткәч, аның хакында белешмә мәгълүмат бирде һәм дога кылды. Нияз хәзрәт быел 16 нчы майда Нурлат төбәгендә Әхмәдзәки хәзрәткә багышлап конференция оештырылачагы турында әйтте һәм бүгенге яшьләрнең чит ил галимнәрен белгәндә үзебезнең бөек дин әһелләрен белмәүләренә борчылуын җиткерде.

Бу юлы искә алырга килүчеләр – чараны оештыручылар һәм кунаклар – дин әһелләре һәм зыялылар яд итүне Габделхак Саматов каберендә дога кылып

тәмамладылар. Мәрҗани мәчете имамы, ТР Диния нәзарәтенең Баш казые булып торганда ихласлыгы, риясызлыгы, дин юлындагы фидакарьлеге белән танылды диеп фикер уртаклаштылар.

Шулай ук бүген күренекле татар зыялыларын да искә алдык. Габдулла Тукай, Туфан ага Миңнуллин, Шамил ага Зиннуров, Миркасыйм ага Госманов каберләре янында тукталып аларны җылы итеп искә төшердек.

Остазларны искә алу чарасы табын артында дәвам итте. Анда остазларга багышлап Корән укыдылар, матур хатирәләр сөйләделәр, мөнәҗәт әйттеләр. Аллаһы вә Сөбханәкә Тәгалә остазларыбызның, күренекле имамнарыбызның барчасына да, күрсәткән фидакарьлекләре, күргән авырлыклары вә газаплары өчен, җәннәт нигъмәтләрен бирсә иде дип дога кылдылар.

Татарстан мөфтие фикеренчә, мәрхүмнәрнең рухына зиратка барып дога кылу яхшы традиция. Доганы планетаның кай почмагында кылсаң да дөрес. Әмма зиратка бару күркәмрәк. Син аңа кунакка киләсең. Үлгән кеше үзенә кем килгәнен белә, аны ишетә. Алар безнең динебезгә хезмәт иткәннәр.

– Без Аллаһыдан аларның гамәлләре савап гамәлләр булып язылсын, дөньялыкта кылган гөнаһларын гафу итүен сорыйбыз, – дип белдерде Камил хәзрәт Сәмигуллин җыелган кунакларга.

Ильяс хәзрәт Җиһаншин җыелган кунакларны алдагы планнар белән таныштырды. Ул сәвит чорында эшләгән имамнар, мөгаллимнәргә багышланган белешмә китабы чыгарырга ният бар диеп, шул мәсәлә турында, фикер уртаклашты. Ильяс хәзрәт мәҗлес ахырында мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинга Мөхәммәд әл-Ходәриның 1917 нче елгы революциягә кадәр дөнья күргән "Нур әл-йакыйн" китабының гарәп телендәге нөсхәсен бүләк итте.

Хәтер чарасы бик матур узды. Барлык катнашучылар да зур канәгатьлек хисе белән таралышты.

## Шәкертләр остазларына эз суытмас

4 май көнне Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе шәкертләре Яңа бистәнең Татар зиратында булды. Алар, биредә күмелгән татар дин әһелләрен барлап, мәрхүмнәр рухына дога кылып кайтты.



Зиратка бару юлында шәкертләр Ак мәчеткә тукталды. Мәдрәсә мөдире Ильяс хәзрәт Җиһаншин, бу мәчет тарихы белән таныштырып, биредә күренекле дин галиме, Коръәнгә тәфсир язган Мөхәммәдсадыйк Иманколый эшләгәнлеген искәртте (Тәсһийлүл-Бәян фи-тәфсирил-Коръән. 1, 2 нче китап. Фарсы теленнән тәфсир итүче Мөхәммәдсадыйк бин Шаһиәхмәд Иманколый әл-Казани. – Казан, 1910-1911). Аның газиз әтисе Шаһиәхмәд хәзрәт Казанның 10 нчы мәчетендә имам булып хезмәт иткән. Бүгенге көндә ул «Ал мәчет» исеме белән билгеле, ягъни бүген биредә Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге югары мөселман мәдрәсәсе урнашкан. Шаһиәхмәд хәзрәт (1803 елда туган) Яңа бистәдәге бу мәчеткә 1834 елда имам булып тәгаенләнә. Ул бик укымышлы хәзрәт була, Бохарада белем ала, күп китаплар язып калдыра.

Бу юлы да искә алу Габделхак хәзрәт Саматов (1930-2009) кабереннән башланды. Совет дәүләте чорында да Мәрҗани мәчетендә имамлык итеп, ТР Диния нәзарәтенең баш казые булып торганда ихласлыгы, риясызлыгы, дин юлындагы фидакарьлеге белән танылган шәхес була. Алай гына да түгел, укуукыту эше белән янып-көеп, 1990 нчы елны ук Чистайда мәдрәсә оештырып, аны 1991 нче елны Казанга күчерә. Икенче булып тукталган Габделхак хәзрәт Каюмов (1921-1999) исә, совет хакимияте елларында, барлык теләгәннәргә дин нигезләрен, гарәп язуын өйрәткән остаз була.

Аннары шәкертләребез Әхмәтзәки хәзрәт Сафиуллин (1896-1995), Габделхәбир хәзрәт Яруллин (1905-1994), Әхмәтһади Максуди (1868-1941), Габдулла Кариев (1886-1920), Габдулла Тукай (1886-1913), Галимҗан Баруди (1857-1921), Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889), Сөнгатулла Бикбулатов (1886-1954) җирләнгән каберләр янына барып, аларның рухларына багышлап догалар кылдылар.

Күренекле татар зыялыларын да искә алдык. Габдулла Тукай, Туфан ага Миңнуллин, Шамил ага Зиннуров, Миркасыйм ага Госманов каберләре янында тукталып, аларны да җылы итеп искә төшердек.

Мәдрәсә мөдире Ильяс хәзрәт Җиһаншин Татар зираты, остазларны искә алу чарасы хакында күп мәгълүматлар бирде. Мондый искә алу чаралары һәр

мәхәлләдә, һәрбер җирлектә оештырылырга тиешлегенә басым ясады һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең хәдисен китерде: “Кабер ул – буш дөнья түгел. Иманлы бәндә өчен ул – җәннәт бакчаларыннан бер бакча, имансыз кеше өчен җәһәннәм чокырларыннан бер чокыр булачак” (Тирмизи).

Безгә бу гамәлне дәвамлы итеп киләчәк буыннарга калдырга кирәк. Үлгәннәрнең каберләрен белеп, кадерләп торсак, киләчәк буыннар безне дә кадерләрләр, онытмаслар.

**Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә шәкертләре сугыш ветераны белән очрашты**

Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе шәкертләре милиция полковнигы, Россия гуманитар фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы, Бөек Ватан сугышы ветераны Харис хәзрәт Салихҗан белән очрашты.

Мәдрәсәбез Харис хәзрәт белән ныклы элемтәдә яши һәм аның белән очрашуларыбыз һәрдаим узып тора. Ул, мәдрәсәбез ачылган елларда, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәнең беренче остазы һәм нигез салучысы Габделхак хәзрәт Саматовта укый.



Харис хәзрәт, быел да, Җиңү бәйрәменә санаулы көннәр калганда, мәдрәсәбезгә килеп, үзенең сугыш чорында күргәннәре белән уртаклашты. “1941 нче елның октябрь аенда әтием Салихҗанны фронтка алдылар. Ул Мәскәү янына эләгә. 110 нчы укчы дивизиядә гади солдат була. Ә 1942 нче елның мартында Боровский шәһәре тирәсендәге бәрелешләрдә каты яралана. Госпитальдә дәвалангач, июнь аенда аны өенә кайтарып җибәрәләр. Әле дә хәтерлим: сул кулы җилкәдән яраксызга чыккан иде. Әти дә, мин дә Балтач районының Чутай авылында туганбыз. Әтине бик ярата идем. Ул гыйлемле, намуслы, хезмәт сөючән һәм дингә бик тә ихтирамлы кеше иде. Гади җир кешесе булса да, латин язуын һәм рус телен үзләштергән иде. Коръән, география, астрономия, математика нигезләрен дә яхшы белә иде. “Мөселман ул – якындагысын аңлаучы һәм ярдәм кулы сузучы”, – дип әйтергә ярата торган иде. Сыңар кулы белән дә хуҗалык эшләрен башкарды, ат җикте, ике арбада иген ташыды”, – дип хатирәләрен яңартты ул.

Харис хәзрәт 1942 нче елда, җиденче сыйныфны тәмамлагач, әтисе кушуы буенча Арча педучилищесына укырга керә. Әмма аны унҗиде яшендә армиягә алалар. 1944 нче елның декабре була бу. Зират яныннан узганда, әтисе аны читкәрәк алып китә һәм: “Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Монда синең бабаң, әбиең ята, ә аларның уллары фронтта. Командирларыңның боерыгын һәрвакыт үтә. Аларның исемнәренә тап төшермә”, – дип үгет-нәсыйхәтләрен бирә. Шушы сүзләр яу кырында аның исеннән бер дә китми...

Очрашу барышында мөхтәрәм хәзрәтебез дин белән фәнне бергә алып барырга кушты. “Схоластика – фанатиклык ул. Динне белү өчен фәнне белергә кирәк. Матди дөньяның иң кечкенә кисәкчеге – атом. Атомнан алып дөнья төзелешенә кадәр булган бар нәрсә Аллаһы Тәгалә тарафыннан бар кылынган. Яралтучыны тану бары динне һәм фәнне тану аша гына мөмкин. Бүгенге көндә Коръәннең утыз процент фәнни өлеше халыктан яшерелгән. Шуның өчен, мин

үземнең “Дин вә фән” китабын балаларны укытуда кулланырга телим”, – дип белдерде очрашу ахырында “Хәтер” мәчете имам-хатыйбы Харис хәзрәт Салихҗан.

Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин очрашу ахырында Харис хәзрәткә Казан шәһәренең Идел буе һәм Вахитов районнары буенча мәчетләр белешмәлеген бүләк итте һәм якынлашып килүче Бөек Җиңү көне белән тәбрикләде.

**Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә шәкертләре “Онлайн ММЧ: мәгълүмат кырында ДАИШка каршы тору” дип аталган халыкара фәнни-гамәли конференциядә катнашты**

Пленар утырышта Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, Мисыр Президентының дини эшләр буенча киңәшчесе Усама Сәйд Әл-Әзһәри, Дәмәшкъ университеты докторы, Левант галимнәре җитәкчесе Мөхәммәд Тәүфыйк Рамазан Әл-Бутый, Иордания университеты профессоры шәех Габдеррәзәк Әс-Сәгъди, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батыров, РФ Эчке эшләр министрлыгының Экспертлар советы әгъзасы Сюкияйнен Леонид Рудольфович, ТР Фәннәр академиясе Ислами тикшерүләр үзәге директоры Патеев Ринат Фаик улы һәм башкалар чыгыш ясады. Утырышта татар дин әһелләренең “Милли тормыш һәм дин” VII форумы делегатлары, Казан мөселман уку йортлары студентлары, шул исәптән Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе шәкертләре дә катнашты.

Очрашу ахырында чит ил уку йортлары белән Татарстан арасында килешүләр имзаланды.

## Мәдрәсәбез вәкилләре “Милли тормыш һәм дин” VII форумында катнашты

"Ни өчен хәзер мөселман өммәте ялган диннәргә каршы тору юлларын эзләргә мәҗбүр соң?! Минем уйлавымча, иң беренче зур сәбәп ул – гыйльми-дини мирасны белмәү. Икенче сәбәп – тәкъвалыкны югалту. Коръәндә Раббыбыз кисәткән: «Котылу һәм өстенлек, әлбәттә, Аллаһудан куркып гөнаһлардан сакланучы тәкъва мөэминнәргәдер». (Нәба (Хәбәр) сүрәсе, 31нче аять). Менә шуны истән чыгармасак иде", – дип җиткерде Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин.

«Милли тормыш һәм дин» VII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумының эшендә барлыгы 916 делегат катнашты. Делегатлар Россиянең Ерак Көнчыгыштан Калининградка кадәр барлыгы 68 төбәгеннән килгән иде.

Форум барышында Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе остазлары һәм шәкертләре чалма чалу буенча мастер-класс үткәрде.

Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә кылган догаларыбызны кабуллардан кылып, ил-көннәребезгә тынычлык-иминлек, бәрәкәт насыйп итсә иде.



**Читтән торып уку бүлеге шәкертләре Рөстәм хәзрәт Батыров белән очрашты**

Рөстәм хәзрәт үзенең чыгышында традицион ислам төшенчәсенә тукталды, аның килеп чыгышы, мәгънәләре һәм әлеге терминның төрле даирә вәкилләре тарафыннан ни рәвешле кулланылуы хакында сөйләде. Ул шулай ук традицион ислам төшенчәсен татарчага тәрҗемә итеп булмавын искәртте һәм моны «Кара-каршы» тапшыруына чакырылган экспертларның да шул көенчә калдырып, тәрҗемәсез сүз алып барулары хакында җиткерде.

Рөстәм хәзрәт традицион ислам төшенчәсенең дүрт мәгънәсенә тукталды: 1) Россия исламы (дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре куллана); 2) халык исламы (этник мөселманнар куллана); 3) татар исламы (милләтчеләр куллана); 4) Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә тоташкан өч дини фән – гакыйдә, фикъһе һәм әхлакый кануннар җыелмасыннан торган ислам, ягъни Әһле сөннәт вәл җәмәгать юлы.

2016 нчы ел Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан Хәнәфи мәзһәбе елы дип игълан ителде. Хәнәфи мәзһәбенең төп үзенчәлеге – аның акылга сыешлы (рациональ) булуында. Әбу Хәнифә бар фикер каршылыкларыбызны да Аллаһы Тәгалә хөкеменә калдырырга кирәк дип әйтә торган булган. Традицион ислам дин галимнәре фикеренчә, Исламда иман төшенчәсе – дингә ышануны тел белән әйтү һәм аны күңелгә, йөрәккә сеңдерү. Иманның өч өлешле булуы турында сөйләгәндә, гамәлләрнең дә иманның бер өлеше булуы турында әйтелә. Мондый фикер буенча, әгәр дә саваплы гамәлләр булмый икән, әйтик, кеше намаз укымаса яки гөнаһлар кылса, мондый кеше кяфер булып исәпләнә.



Рөстәм хәзрәт үз чыгышында Болгар дәүләтенә өч сәхабә килү вакыйгасын да читләтеп үтмәде. “Безгә бу фактка фәнни яктан

түгел, дини яктан карарга кирәк”, – диде ул. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләре болгар бабаларыбызга дин алып килгәндә чалма, юл таягы һәм кара савыты белән килгәннәр. Чалма ул – фани дөньядан бакыйга китәргә, Аллаһы Тәгалә белән очрашырга әзерлек билгесе; юл таягы – тынычлык символы (кайбер илләрдә аның урынына хәзер хәтта утлы корал тоталар); кара савыты – гыйлемлелек, рациональлек билгесе.

Очрашу ахырында мәдрәсәбез мөдире Ильяс хәзрәт Җиһаншин Рөстәм хәзрәткә борынгы Коръән китабы бүләк итте. Рөстәм хәзрәт озакламый Мәрҗани йортында Ислам мәдәнияте музее ачылачагы турында искәртте һәм шул музейны мөмкин кадәр тарихи мирас ядкярләре белән тулыландыруда актив катнашырга чакырды.

## Читтән торып уку бүлеге шәкертләре Яңа бистәдәге Татар зиратын зиярәт кылды

25 май көнне Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсенең читтән торып уку бүлеге шәкертләре Казан шәһәренең Яңа бистә Татар зиратында булды. Алар, биредә соңгы сыену урыны тапкан татар дин әһелләре белән танышып, мәрхүм хәзрәтләр рухына дога кылды.

Бу юлы да искә алу Габделхак хәзрәт Саматов (1930-2009) кабереннән башланды. Ул совет дәүләте чорында да Мәрҗани мәчетендә имамлык итеп, ТР Диния нәзарәтенең баш казые булып торганда ихласлыгы, риясызлыгы, дин юлындагы фидакарьлеге белән танылган шәхес була. Алай гына да түгел, уку-укыту эше белән янып-көеп, 1990 нчы елны ук Чистайда мәдрәсә оештырып, аны 1991 нче елны Казанга күчерә. Икенче булып тукталган Габделхак хәзрәт Каюмов (1921-1999) исә, совет хакимияте елларында, барлык теләгәннәргә дин нигезләрен, гарәп язуын өйрәткән остаз була.

Аннары шәкертләребез Әхмәтзәки хәзрәт Сафиуллин (1896-1995), Габделхәбир хәзрәт Яруллин (1905-1994), Әхмәтһади Максуди (1868-1941), Габдулла Кариев (1886-1920), Габдулла Тукай (1886-1913), Галимҗан Баруди (1857-1921), Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889), Сөнгатулла Бикбулатов (1886-1954) җирләнгән каберләр янына барып, аларның рухларына дога кылдылар.

Күренекле татар зыялылары да читтә калмады. Габдулла Тукай, Туфан ага Миңнуллин, Шамил ага Зиннуров, Миркасыйм ага Госманов каберләре янында тукталып, аларны да җылы итеп искә төшердек.

Мәдрәсә мөдире Ильяс хәзрәт Җиһаншин Татар зираты, остазларны искә алу чарасы хакында күп мәгълүматлар бирде. Мондый искә алу чаралары һәр мәхәлләдә, һәрбер җирлектә оештырылырга тиешлегенә басым ясады һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең хәдисен китерде: “Кабер ул – буш дөнья түгел. Иманлы бәндә өчен ул – җәннәт бакчаларыннан бер бакча, имансыз кеше өчен җәһәннәм чокырларыннан бер чокыр булачак” (Тирмизи). Шулай ук алдан маршрут-схема төзелүе һәм каберләрне ерактан танып алу өчен тамгачыклар куелуы да искәртелде.

Безгә бу гамәлне дәвамлы итеп киләчәк буыннарга калдырга кирәк. Үлгәннәрнең каберләрен белеп, кадерләп торсак, киләчәк буыннар безне дә кадерләрләр, онытмаслар.

## Профессор лекция сөйләде

27 май көнне Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсенең читтән торып уку шәкертләре тарих фәннәре докторы Наил Исмәгыйль улы Таиров белән очрашты.



Ул читтән торып уку бүлеге шәкертләренә лекция сөйләде. Лекция темасы Габдулла Тукайның 130 еллыгына багышланган иде – “Габдулла Тукай һәм танылган фабрикант һәм меценат Акчуриннар”. Бер фрагмент –шагыйрьнең танылган сәүдәгәр, фабрикант һәм меценат Хәсән Акчуринга кунакка баруы сөйләнде. Акчуриннарның Габдулла Тукайга мөнәсәбәтләре яхшы булган дип әйтергә була, аның иҗаты белән кызыксыннар, Тукай вафат булгач аның исемен мәңгеләштерү юлында да зур эшләр эшләгәннәр.

Наил абый Таиров читтән торып уку бүлеге шәкертләре белән Казанның Яңа бистә зиратында күренекле шәхесләребезне зиярәт кылуда катнашты.

**Мәдрәсәдә баш казый дәрес бирде**

Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсендә Татарстанның баш казые, Балтач районы имам-мөхтәсибе Җәлил хәзрәт Фазлыев катнашында “Рамазан аен каршылап” дип исемләнгән очрашу-дәрес узды.



Һиҗри исәп буенча 1437 нче елның рамазан ае башланырга да ун көннән азрак вакыт калып бара. Изге айга әзерлек йөзеннән, мәдрәсә җитәкчелеге читтән торып уку бүлегендә белем алучы шәкертләр өчен махсус чара оештырды. Әлеге чараны үткәрүчеләргә, аерым алганда, мәдрәсә мөдире Ильяс хәзрәт Җиһаншинга рәхмәт белдереп, очрашуга килгән Җәлил хәзрәт шәкертләрнең уразага кагылышлы сорауларына җавап бирде, рамазан аен үткәрү барышында, ифтарлар үткәргәндә халык арасында, җәмәгатьчелектә килеп чыга торган кайбер мәсьәләләргә аңлатмалар биреп үтте һәм шулай ук мәчет-мәхәлләләрдә имам булып хезмәт итүчеләргә тәҗрибәсеннән чыгып, үзенең киңәш-нәсыйхәтләрен дә җиткерде.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисендә килгәнчә, айларның иң олугысы – рамазан ае. Әлеге айның әһәмияте турында Җәлил хәзрәт очрашуда катнашучыларга түбәндәгеләрне җиткерде:

– Адәм баласының асылы ике асылдан гыйбарәт. Аңарда нәфес бар — хайвани асыл һәм акыл, аң бар — монысы фәрештәләрдән килгән асыл. Адәм баласының бөтен яшәеше шушы ике асылының көрәшеннән гыйбарәт. Гомер буе адәм баласының нәфес белән аңы көрәшә. Аллаһы Раббыбыз Коръәни-Кәримдә «Әт-Тин» («Инҗир агачы») сүрәсенең 4 нче аятендә: “Мин акыл биреп, сезне бөтен мәхлукаттан өстен иттем”, — ди. Кем үзенең акылы белән, аңы белән нәфесен җиңә алса – ул кеше Аллаһы Тәгалә хозурында фәрештәләрдән дә өстен булыр. Шушы сүрәнең 5 нче аятендә Аллаһы Раббыбыз: “Мин кайберәүләрне түбәннән дә түбән төшерермен”, — ди. Болары кемнәр? Болары — нәфесләрен акылларыннан өстен куючылар, ягъни өстенлекне нәфескә биргән кешеләр. Һәм алар турында Аллаһы Раббыбыз: “Түбәннең дә түбәненә, хайваннан да түбәнгә төшәрләр”, — дип әйтә. Без үзебезнең тормышыбызда моның мисалын ачык күрмибезмени: дуңгыздан да, хайваннан да яманрак булып аунап ятучылар юкмыни? Балаларына, әти-әниләренә кул күтәргән кешеләрне белмибезме? Менә бу — хайваннан да түбән төшү түгелме? Бер генә хайван да баласын каһәрләми. Бер генә хайванның да баласы яшь вакытта ата-анасын каһәрләми. Бер генә хайван да баласын үтерми. Без үзебезнең бозыклыгыбыз белән, нәфес артыннан куыбыз белән түбәннән дә түбән баскычка төшәбез.

Әмма Аллаһы биргән рамазан ае, ураза безгә нәфесебездән өстен икәнебезне, аны җиңә алуыбызны күрсәтергә мөмкинлек бирә.

Ахырдан: “Без рамазан-шәрифтә үзебезнең Аллаһы хозурына барасыбызны бигрәк тә еш исебезгә төшерергә тиеш. Аның каршында җавап тотасыбыз бар. Адәм балалары каберләреннән ашыйсылары килеп, гаҗиз булып кубарылырлар. Ә рамазан аенда ураза тоткан кешеләр исә хуш ис белән кубарылырлар, фәрештәләр аларның тамагын туйдырып, сөаль вакытында, сөаль мәйданында алар ачлык һәм эчәсе килүнең нәрсә икәнен белмәсләр”, – дип җиткерде Җәлил хәзрәт.

Очрашу барышында күп кенә сорауларга ачыклык кертелде. Әйтик, фидия яисә фитыр сәдакаларын тапшыру, тәравих намазларын укыту, гает намазын үткәрү, яшүсмерләрне заман афәтләреннән саклау буенча тәфсилле җаваплар булды.

Дәресне тыңлаучыларга Җәлил хәзрәт “Локман хәким нәсыйхәтләре” китабының өченче басмасы дөнья күрү турында хәбәр бирде һәм аны мәдрәсәбез китапханәсенә бүләк итте.

**Мәдрәсәдә диплом тапшыру тантанасы узды**



3 июнь көнне Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсенең читтән торып уку бүлеген тәмамлаган 19 шәкерткә дипломнар тапшырылды.

Чыгарылыш курс шәкертләрен өч ел дәвамында укып, имтиханнарны яхшы тапшырып һәм диплом эшләрен уңышлы яклаулары белән мәдрәсә ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин тәбрикләде. Ул пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисен китерде: “Гыйлем иясе (галим), яки гыйлем алучы (шәкерт), яки гыйлемне тыңлаучы, яки гыйлемне сөюче бул. Ләкин бишенчесе (гыйлемне дошман күрүче) булма, һәлак булырсың”. Моннан аңлашылганча, һәркайсыбызга гыйлемле, белемле булырга омтылып, гыйлемне башкаларга да өйрәтү тиеш булуы хакында әйтелде һәм шушы әманәтне бүтәннәргә тапшыруның әһәмияте җиткерелде. Ильяс хәзрәт, сүзен йомгаклап, мәдрәсәне тәмамлаучыларны гыйлем үзләштерү һәм аны тарату юлында тукталмаска өндәде. Укучылар тәрбияләүдә һәм яшь буынны динле итеп үстерү эшендә уңышлар юлдаш булуын теләде.

Әлеге истәлекле вакыйгада күп кунаклар катнашты. Алар мәдрәсә тарихы белән танышты, үзләренең ихлас теләкләрен җиткерде.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең мәгариф һәм фән бүлеге мөдире Айдар хәзрәт Карибуллин бишектән ләхеткәчә гыйлем алуның зур бурыч булуы хакында сөйләде һәм Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсенең республикабыз мәчетләренә имамнар әзерләүдә үрнәк булуын әйтеп узды, мәдрәсәбез ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншинга алга таба да эшендә уңышлар теләде.

Аннары уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары Аяз хәзрәт Мингалиев сүз алды. Ул пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисен китерде: “Кем дә кем гыйлем алу юлына басса, Аллаһы аңа җәннәткә алып баручы юлны җиңеләйтә”. Аяз хәзрәт шәкертләргә гыйлем алу юлыннан беркайчан да читкә тайпылмаска чакырды.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров белемле кеше булып саналыр өчен биш шартны үтәргә кирәклекне әйтте: 1) остазыңны игътибар белән тыңларга; 2) дәрес вакытында сөйләшмәскә; 3) остазның сүзләрен истә калдырырга тырышырга; 4) алган белемнәреңне тормышта кулланырга; 5) белемнәрне башкаларга да ирештерергә. Нияз хәзрәт: “Сезнең һәрбарчаларыгызга да зур уңышлар телим, барыгызга да гыйлем алуны дәвам итәргә, Аллаһы ризалыгы өчен изге гамәлгыйбадәтләр кылып яшәргә насыйп булсын”, – дип, ихлас теләкләрен тапшырды.

Бөтендөнья татар конгрессының Казан шәһәре бүлеге җитәкчесе Фәрид Мифтахов милли гореф-гадәтләребезне онытмаска, динне һәм милләтне һәрвакыт бергә, бер-берсеннән аермыйча алып барырга боерды. Шулай булганда гына дин белән милләт бер-берсен тулыландырыр һәм туган телебезне үстерү, аны саклау һәм өйрәнү юлында яңа мөмкинлекләр туар дигән теләген белдерде.

Мәдрәсәбез остазы Ибраһим хәзрәт Шамилов чын күңелдән гыйлем үзләштергән барлык шәкертләргә дә рәхмәт сүзләрен җиткерде һәм динебез юлында армый-талмый озак еллар бергә хезмәт итүебезне теләде.

Тарих фәннәре докторы, профессор Наил Таиров 1917 нче елгы революциягә кадәр дин әһелләренең һәм татар имамнарының зур абруйга ия булуларын әйтеп узды һәм бүгенге көндә дә авылларда аларның универсаль шәхесләр булып калуларын яшермәде. “Муллалар һәрвакыт мәхәлләгә зур таяныч булган, авыр вакытлар да, шатлыклы көннәр дә халык белән бергә узган: алар мөгаллим дә, психолог та, табиб та, гомумән, авылда әйдәп баручы, мәхәлләне җитәкләүче булганнар”, – диде ул.

Шуннары унтугыз шәкерткә урта дини белем алу хакында дипломнар тапшырылды, җомга намазы укылды.